Диндә көчләү юк, ләкин өндәү һәм өйрәтү бар”
(Коръән Кәрим. 2-256)

# Ислам Нуры

№ 8 (636) 25 апрель, 2017 ел (1438, Рәҗәб) Дини-иҗтимагый газета 1995 елдан чыга

12+

## Татарстан мөселманнарының VII Корылтае



17 апрельдә Казанның “Корстон” кунакханәсендә Татарстан мөселманнарының чираттагы VII Корылтае узды. Чара Коръән аятьләре укып һәм дога кылып башланды. Беренчеләрдән булып делегатларны Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов сәламләде.

Мөфти Камил хәзрәт Сәмигуллин һәм баш казый Җәлил хәзрәт Фазлыев 2013-2017 елларда башкарган эшчәнлеккә нәтиҗәләр ясады. Шулай ук делегатлар игътибарына нәзарәтнең үзәк ревизия комиссиясе хисабы да тәкъдим ителде.

Камил хәзрәт үзенең чыгышында 4 ел дәвамында башкарылган эшләрдән тыш, киләчәктә мөселман өммәте каршында торган бурычларны да барлады. Бүгенге көндә нәзарәт составына 1415 теркәлгән мәхәллә һәм 1430 мәчет керә. Аларда 1400 имам хезмәт итә. Бу - Россия Федерациясендә эшләп килгән бөтен мәхәллә һәм мәчетләрнең чирегеннән артык. Шул ук вакытта соңгы 4 ел эчендә генә республикада 50дән артык яңа мәчет ачылган.

Камил хәзрәт үз чыгышында башка юнәлешләрдә башкарылган эшчәнлек белән дә таныштырды. Ул киләчәккә төп бурычларның берсе итеп Ислам мәгарифен яңа югарылыкка күтәрү, шәригать фәннәре буенча магистр яки фән докторы дәрәҗәсендәге белгечләр әзерли башлауны атады. Камил хәзрәт шулай ук имамнарның җәмгыятьтәге абруен күтәрүне, мөселман дин әһелләренең кадрлар резервын туплауны, зыялылар әзерләүне мәктәпләрдән үк башлауны мөһим бурыч итеп атады.



Хисап чыгышларыннан соң мөфти, аның беренче урынбасары, баш казый һәм үзәк ревизия комиссия әгъзаларын сайлау булды. Делегатларның күпчелек тавышы белән мөфти итеп Камил хәзрәт Сәмигуллин, беренче урынбасары итеп Рөстәм хәзрәт Валиуллин, баш казый итеп Җәлил хәзрәт Фазлыев сайланды.

Шулай ук Корылтайда катнашучылар нәзарәтнең уставына үзгәрешләр дә кабул итте. Корылтай ахырында аерым дин әһелләренә дәүләт бүләкләре тапшырылды. Форум Коръән укып тәмамланды.

## Фәезханов укулары Батырша хәзрәтләренең тууына 300 ел тулуга багышланды

**11-12** апрельдә Санкт Петербург шәһәрендә традицион фәнни-гамәли конференция — “XIV Фәезханов укулары” узды. Ул “Күп динле Рәсәй дәүләтендә Хакимият һәм җәмгыять” темасына багышланды. Шулай ук конференция кысаларында Идел буе һәм Урал мөселманнары тарихында мәшһүр роль уйнаган Габдулла Галиевнең (Батырша) тууына 300 ел тулу вакыйгасы билгеләп үтелде. Форумның төп өлеше Нева проспектында урнашкан дәрәҗәле “Талион империал отель”дә барды. Конференцияне РФ мөселманнары Диния нәзарәте, Санкт-Петербург дәүләт университеты, Мәскәү ислам институты оештырдылар.

Конференция кабул иткән резолюциядә күпдинле һәм күпмилләтле дәүләтнең тотрыклы үсеше хакимият структураларының һәм җәмгыятьнең гражданлык тотрыклылыгы өчен тырышучы төрле-төрле категорияләре вәкилләре белән булган диалогы, бергә эш итүе шартларында гына мөмкин булуы, күп гасырлар



буе Рәсәй дәүләтенең территориаль бөтенлеген һәм бердәмлеген җәмгыятьнең мөселман һәм христиан өлешләренең ныклы, тотрыклы бәйләнешләре тәэмин итүе ассызыклап әйтелә. Шулай ук анда Хөсәен Фәезхановның Кырым ханлыгы тарихына, татар теле грамматикасына кагылышлы хезмәтләрен урысчага тәрҗемә итеп бастырып чыгару, Санкт-Петербург һәм Ленинград өлкәсе хакимиятләренә Петропавловск һәм Шлиссельбург крепостларына Габдулла Галиевка (Батырша) истәлек такталары кую, Батырша чуалышларына бәйле архив документларын бастырып чыгару, 2018 елда узачак “Фәезханов укуларына” әзерлекне башлау һ.б бурычлар билгеләнә.




Ошбу конференция эшендә Башкортостанның Балтач районындагы Батырша хәзрәтләре музее директоры, район имам-мөхтәсибе Рафис Муллагаттәр улы Шәйхәйдаров та катнашты. Ул бу уңайдан менә нәрсәләр дип бәлдерә:

— Конференция искитәрлек дәрәҗәдә әзерләнгән иде, бик күп чыгышлар булды. Икенче кеше итеп сүзне миңа бирделәр. Һәм инде шушы сүземдә мин Батырша хәзрәтне мәңгеләштерү юнәлешендә алып барылган эшләр турында сөйләдем, аның музеен, аның турында үткән гомум-фәнни конференцияләрне, чыккан китапларны, төрле басмаларда басылган мәкаләләрне, музей экспозицияләрен, Батырша хәзрәт белән бәйле тарихи урыннарны җентекләп телгә алдым. Халык телендә сакланган, инде гасырлардан килгән Батырша чокыры (туган авылы Карыштан 6-7 чакрым), Батырша урманы, Батырша күле — алар бүгенге көндә дә шул исем белән йөртелә. Башкортостан хөкүмәтенең карары белән Югары Карыш тулы урта мәктәбенә Батырша хәзрәт исеме бирелде. Балтач районының Җәмигъ мәчете Батырша хәзрәтнең исемен йөртә. Шул мәчет янында гына аның йорт-музее эшләп килә. Үткән ел республикабыз башкаласының матур бер урамына Батырша хәзрәтнең исеме бирелде.

Батырша хәзрәт ике ел Петропавловск крепостендә, дүрт елдан артык

Шлиссельбург крепостендә тотыла. Шул соңгы крепостны карасак, анда кемгә генә истәлек тактасы куелмаган — шведларга да, полякларга да, революционерларга да, Бөек Ватан сугышында катнашучыларга да. Ә инде безнең Бөтен Идел-Урал һәм Рәсәй мөселманнарының иң зур вәкиле һәм күренекле шәхесе, Рәсәйдә көчләп чукындыруны туктатуга сәбәпче булган, үзенең гомерен корбан иткән Батырша хәзрәтләренең исеме анда беркайда да күренми. Батырша хәзрәтләре 1762 елның 24 июлендә шәһит китә. Шул вакыттан башлап патша заманында аны искә алырга ярамый. Чөнки патшага каршы көрәшче була. Инде совет вакытында да искә алырга ярамый. Чөнки дин әһеле була. Ә инде безнең — аның варисларының, якташларының һәм Ислам динен тотучы барлык халыкның бурычы - андый кешеләрне онытмау, аларга догада булу, аларның исемен мәңгеләштерү, аларның яшәешләрен үзебезгә үрнәк итеп алу. Бу безнең вазыйфабыздыр.

Конференөия кысаларында башка программалар да бар иде. Мәсәлән, Санкт-Петербург Ислам оешмасының яңадан теркәлүенә бер ел үтүгә бәйле рәвештә кичке аш мәҗлесе тәкъдим иттеләр. Мәскәү мәчете имамнары сурәтләреннән торган стенд эшләнгән иде. Мәскәү мәчете нигезләнгәннән башлап 13 имам булган икән. Һәм инде Рәсәйдә булган мөфтиләрнең сурәтләрен тәкъдим иттеләр. Алар да 13 икән. Сурәтләре чын талант ияләре тарафыннан эшләнгән, бик матур. Һәм шушында ук Ислам диненә багышланган, чүкеп эшләнгән шәмаилләр, Ислам диненә кагылышлы кайбер тарихи шәхесләрнең сыннары да куелган иде. Мәдәни өлеше дә бик эчтәлекле булды.

**Рәсемдә:** Рафис хәзрәт (үнда) конференциядә катнашучы Башкорт тел, әдәбият институты бүлек мөдире Марсель Фәрхшатов, РФ мөселманнары Диния нәзарәте мөфтиенең I урынбасары Дамир хәзрәт Мөхетдинов белән.

# Тырышлык

Аллаһы тәгалә әйтә: (28.77.) «Бәлки Аллаһ биргән малны Аллаһы юлына биреп ахирәтне кәсеп ит, дөньядан да үз өлешеңне онытма, ахирәтең өчен гамәл кыл, Аллаһ сиңа ихсан кылып мал биргән кебек син дә мохтаҗ кешеләргә малыңнан бир, җир өстендә явызлык белән бозыклык кылып йөрмә, тәхкыйк, Аллаһ бозыклык кылучыларны сөйми».

Бу аятьтә Аллаһы тәгалә безгә ахирәт өчен дә, дөньялык өчен дә тырышлык куюны боера. Әлбәттә, адәм баласы гыйбадәт кылу өчен халикъ кылына һәм бу хакта безне искәртеп Аллаһы тәгалә әйтә: (51.56.) «Кеше белән җенне Мин фәкать үземә генә гыйбадәт кылсыннар өчен халикъ кылдым».

Әмма дөрес аңларга кирәк: адәм баласының гыйбадәте 5 баганаsucc үтәү белән генә чикләнми, аның һәр гамәле, мизгеле гыйбадәт булып тора. Адәм баласы ихтыяҗлар белән яратылган: ул ашый, эчә, киенә, гаилә кора, балалар үстерә, тормышын билгеле бер җәмгыятьтә алып бара. Үзенең шушы ихтыяҗларын канәгатьләндерер өчен ул кирәк вакытта шыбыр тиргә батып зур тырышлык күрсәтергә дә, кирәк вакытта зур сабырлыкка да ия булырга тиеш. Бу ике сыйфатка ия булу адәм баласыннан дөнья эшләрендә дә, дини гыйбадәтләр башкарганда да таләп ителә, ягъни ул үзе, гаиләсе ач булыр дәрәҗәдә дөнья эшләрендә ялкау булып, дини гыйбадәтләргә генә дә бирелергә тиеш түгел, яисә дөнья эшләренә генә бирелеп, кирәгенннән артык дөнья куып ахирәтен онытыр дәрәҗәгә дә җитәргә тиеш түгел. Ул пәйгамбәребез салл-Аллаһу галәйһи вә сәлләм кушканча тиешле бер урталыкны сайларга бурычлы. Хәләл юл белән шәригать чикләрендә алып барылган хезмәт шулай ук диннең бер өлеше, мөселман кешенең өстенә йөкләтелгән бурычы.

Пәйгамбәребез салл-Аллаһу галәйһи вә сәлләм әйтә: «Хәләл хезмәт таләп итү — һәрбер мөселманның бурычы». (әл-мөгҗәм әл-әусат әт-Табарани, 8848)

Хәтта пәйгамбәрләр дә хезмәтне үзләренең бурычы итеп саныйлар һәм хезмәттә зур тырышлык күрсәтәләр. Бөтен пәйгамбәрләр дә үзләре эшләп тапкан белән генә көн итәләр.

Рафигъ ибне Хадиҗдән риваять кылына, Кешеләр: «Я, Расүлуллаһ, нинди кәсеп иң яхшысы?», дип сорадылар. Ул әйтте: «Кешенең үз кулы белән эшләве һәм һәрбер гадел сәүдә итү» (имам Әхмәд мөснәде, 17728).

Пәйгамбәребез салл-Аллаһу галәйһи вә сәлләм башка пәйгамбәрләрне искә алып әйтә: «Давыд галәйһиссәләм үз куллары белән эшләп тапкан ризыкны гына ашый иде», һәм шулай ук Зәкәрия галәйһиссәламне искә алып: «Зәкәрия галәйһиссәлам балта остасы иде». ди.

Дөньяларын тәзек алып бару пәйгамбәрләрнең гыйбадәтләренә кимчелек китерми. Ә пәйгамбәрләр исә бөтен эшләрдә дә, гыйбадәтләрдә дә башкаларга мисал булып торалар.

Кагб бине Әҗәдәдән риваять кылына: «Бервакыт Аллаһының илчесе үзенең сәхәбәләре белән утыра иде, алар янынннан тиз-тиз атлап бер кеше узып китте. Сәхәбәләр әйттеләр: «Әй, Расүлуллаһ! Әгәр аның ашыгучанлыгы һәм җитдилеге Аллаһ юлында булса иде!», дип. Расүлуллаһ салл-Аллаһу галәйһи вә сәлләм әйтте: «Әгәр ул үзенең кечкенә баласы өчен хезмәт итсә, бу Аллаһ өчен була. Әгәр ул үзенең карт әти-әниләре өчен хезмәт итсә, бу Аллаһ өчен була. Әгәр ул үзе өчен хезмәт итсә, бу Аллаһ өчен була. Әгәр инде ул үзен күрсәтү өчен, яисә мактану өчен хезмәт итсә, бу шайтан юлы була».

Дөнья һәм ахирәт өчен булган тырышлык тигез булганда гына гыйбадәт дөрес булырга мөмкин. Икесен дә дөрес аңлап икесенә дә тигез тырышлык куярга кирәк. Фәнгә, дөньяга битараф калган ислам илләре бүген көнбатыш илләренә бәйлелектә. Ислам дөньясында бүген кан койгыч сугыш бара. Бу сугышта дөньядагы соңгы фән казанышларын, алдынгы технологияләр кулланып ясалган танклар, самолетлар һ.б. техникалар кулланыла. Ислам дәүләтләре үзләре бу сугыш коралларын җитештермиләр бит. Һәм бу кораллар мөселманнарның бер-берсенә каршы кулланыла. Ә корал бирүчеләр һәм сугышны оештыручылар үзлре бу сугыш мәйданында катнашмыйлар. Ә шул ук вакытта Исламга битараф булып, хәтта дошман булып фәнгә, дөньяга зур тырышлык куйган Көнбатыш цивилизациясе бүген әхлаксызлык упкынына төшеп үзенең әҗәленә якынлаша. Динне дөньяга зыян сала, илнең алга китүен тоткарлый, дип дин әһелләрен асып, сөргенгә сөреп тырышып «коммунизм» төзегән совет иле таралды, халкы көлкегә калды. Бу халык бүген дә үзенең адашуыннан айный алмый: үзен мөселман санаса да «яңа ел»ны да каршы ала, 8 мартын да бәйрәм итә, башкалардан калышмыйм, дип мәңгелек ут янында да басып тора, аракылы туй мәҗлесләрен уздырудан да чиркәнми, ә шул ук вакытта исламның төп ике бәйрәме булган корбан һәм рамазан гаедләрен игътибарсыз калдыра. Монда бик әһәмиятле бер нәрсәгә игътибар итәргә кирәк: ислам гыйбадәтләрен үтәмәгән, бәлки мәҗүсиләрнең гыйбадәтен үтәгән кешене мөселман дип әйтеп була микән?

Пәйгамбәребез салл-Аллаһу галәйһи вә сәлләм әйтә: «Иман белән гамәл икесе бертуганнар, һичкайсы ялгыз гына эшкә ярамас»

Тырышлыкны бүген күпләр дөрес аңламыйлар. Үзләре тырышмыйча гына башкаларны тырыштырырга теләүчеләр артык күбәеп киттеләр. Бер яклап дөнья эшендә: кайбер байларның, түрәләрнең күзләренә мәдрәсә шәкертләре советлар союзы вакытындагы «тимурчылар» булып күренәләр, бу шулай ук кайбер әби-бабайларга да кагыла: балаларның, оныкларның вакытлары юк, шәкертләр бакча казымаслармы, башка кайбер эшләрне эшләмәсләрме, дип шәкертләрне сорыйлар. Икенчеләре, бу категориягә күбрәк яшьләр керә, «КамАЗ» һәм башка оешмалар кәфер оешмалары, анда эшләргә ярамый дип ата-ана сыртында эшләмичә ятарга телиләр. Шулай ук кәферләрне алдарга, малларын талап алырга ярый, дип җиңел кәсеп эзләп җинаять юлына кереп китүчеләрне дә күрергә туры килә. Дини эшләрдәге тырышлыкка килгәндә, хәреф танымаган, кулына комган тотып тәһарәт тә ала белмәгән, намазларын да тиешенчә укымаганнарның дин өйрәтүләре, мәзһәб мәсьәләләрен тикшерүләре, кемнең намазы дөрес, кемнеке дөрес түгел икәнлекләрен тикшереп йөрүләре. Үзләренә тырышып дин өйрәнәсе урынга, динсезләрне дингә өндисе һәм үз гыйбадәтләрен тиешенчә җиренә җиткереп үтисе урында, кайберәүләр мәчеткә килгәннәрнең гыйбадәтен тикшерүгә зур тырышлык куялар. Халкыбыз арасында үзләрен мөселман санаучылар бик күп, ә инде ризыкның, кылына торган гамәлләрнең хәләллегенә-хәрамлыгына игътибар итүчеләр бик аз. Бу иманның телдә генә булуын, күңелләргә үтеп кермәвен күрсәтә. Иманы бар кеше кыямәт көненнән куркыр иде, хәрамның үзе өчен булган нәрсәләрнең иң хәерсезе икәнлеген аңлар иде. Пәйгамбәребез салл-Аллаһу галәйһи вә сәлләм әйтә:

«Аллаһ тыйганны ашауга караганда бер уч ком ашау хәерлерәк.»

Әлбәттә, кешенең гамәлен, гыйбадәтен тикшерү үзеңә үтәүгә караганда күпкә җиңелрәк. Эшләгән кешенең кимчелеге булмый калмый, ә эшләмәсәң бер кимчелегең дә булмый. Үзең эшләмичә башкаларны тикшерү, ялкаулар өчен бетмәс эш. Ә инде иң ялкаулары мөселманнар дөньяда кайгы-хәсрәттә яшәп, ахирәттә бәхетле булырбыз дип гаиләләрен ташлап кайгы-хәсрәткә омтылалар.

Дөньяның төрле кайнар нокталарына сугышка китү дә, минемчә, шул ялкаулыкның бер төре генә. Көн-төн эшләп гаилә туйдырасы юк, баланы ничек тәрбиялим икән, ничек аңардан кеше ясыйм икән дип борчыласы юк, Сүриягә барасың да сугышасың: үлмәсән сине шәйх туйдыра, үлсәң җәннәткә керәсең. Әмма анда мөселман белән кәфер түгел, бәлки, алда әйтеп кителгәнчә, мөселман белән мөселман сугыша. Ә сөекле пәйгамбәребез Мөхәммәд салл-Алаһу галәйһи вә сәллам әйтә: «ике мөселман берсенә каршы берсе кылыч күтәрсә, үлгәненең дә үтергәненең дә урыны җәһәннәмдә".

Пәйгамбәребез салл-Аллаһу галәйһи вә сәлләм әйтә:

«Дөнья өчен һич үлмәс кебек тырыш, ахирәт өчен иртәгә үләчәк кеше кебек тырыш», ди.

Пәйгамбәребез Мөхәммәд салл-Аллаһу галәйһи вә сәлләмнең иң күп догасы: (2.201.) «Әй, Раббыбыз, безгә дөньяда да, ахирәттә дә изге нигъмәтләреңне бир. Һәм безне җәһәннәм газабыннан сакла.»

Пәйгамбәребез гадәйһиссәлам ике дөньяда да изге нигъмәтләр сораган. Һәм Аллаһы тәгалә бу нигъмәтләрне аңа биргән кадәр беркемгә дә бирмәгән. Ул үлгәндә Гайшә анабыз йортында мохтаҗларга таратырга дигән 6-7 динар акчадан башка бернәрсә дә калмаган була. Бер вакыт, пәйгамбәребез салл-Аллаһу галәйһи вә сәлләмнең вафатыннан соң, Әбү Һөрәйра базар халкына мөрәҗәгать итеп: «Әй, кешеләр! Мәчеттә пәйгамбәребез салл-Аллаһу галәйһиссәламнең мирасын бүлешәләр,» дип әйтә. Бөтен кеше мәчеткә йөгерә һәм алар мәчеттә мал бүлешүче кешене күрмиләр. Алар кире әйләнеп кайталар һәм анда кешеләрнең бернәрсә дә бүлешмәгәннәрен әйтәләр. Ул алардан, ә кешеләр анда нәрсә белән шөгыльләнәләр соң, дип сорагач, алар анда кайберәүләрнең Коръән укулары, кайберәүләрнең зикер әйтеп утырулары, кайберәүләрнең дәрес алулары турында әйтәләр. Шунда ул: «шушы бит инде пәйгамбәребез галәйһиссәламнең мирас малы,"- дип әйтә.

Аллаһы тәгаләнең иң зур нигъмәте - безнең

Ислам динендә булуыбыз. Безнең ризыгыбыз, булган һәм булачак малларыбыз безгә инде ана корсагында вакытта ук, 4 айлык чагыбызда ук, җаныбыз кергән вакытта ук язылып куелган. Шуңа күрә дөньяны күпме генә кусаң да артыгына ирешә алмаячаксың. Кайберәүләр Аллаһы тәгаләнең рәхмәте дөнья малында, аның күләмендә дип ялгыш фикердә. Әгәр дә Аллаһының рәхмәте дөнья малында булса, дөнья малы пәйгамбәребез галәйһиссәламгә бирелер иде. Шулай ук мал ана корсагында вакытта ук язылган дип эшләмичә яту да рөхсәт ителми. Монысы инде ялкаулык була.

Мөселманнар бөтен эштә дә башкаларга үрнәк булырга тиешләр. Шуңа күрә дөнья эшендә дә тырышлык күрсәтергә кирәк. Кемнәндер өмет итүгә караганда, өмет итүчеләргә бирү хәерлерәк. Пәйгамбәребез салл-Аллаһу галәйһисәлам: «өстәге кул астагы кулдан хәерлерәк», ди. Без спортсменнарның, артистларның ничек бай яшәгәннәре турында сөйләргә яратабыз, ә алар бай яшәр өчен ничек тырышалар. Дөресен әйтергә кирәк, дин эшләрендәге безнең тырышлык спортсменнар һәм артистлар белән чагыштырып булмас дәрәҗәдә түбәндер. Дин эшләрендә дә башкаларга үрнәк булырга кирәк. Бер-беребезнең кимчелеген эзләгәнче, динсезләрне дингә өндәргә кирәк. Бу эштә бөтен кешегә дә эш җитә. Мөселман булмаганнар мөселманнардан күпкә күбрәк.

Бүген тырышлык турында аңлатырга тырыштым. Ахирәтне өмет итеп тырышуның сүлпәнлеге шайтан вәсвәсәсе белән бәйле. Бу ахирәтне өмет итеп башкарылган дөньяви һәм дини гамәл-гыйбадәтләрнең барчасына да кагыла. Онытмыйк, кыямәт бик якын. Үкенүчеләрдән булмыйк, мөмкинлек барында тырышып калыйк.

Пәйгамбәребез салл-Аллаһу галәйһи вә сәлләм әйтә:

«Җиде нәрсәгә ирешкәнче хәерле изге гамәлләрегезне эшләп калыгыз. Ул җиде нәрсә түбәндәгеләр:

1. Гыйбадәтләрне, хәләл һәм хәрамны оныттыра торган фәкыйрьлек.
2. Бозыклыкка китерә торган байлык.
3. Бөтен нәрсәне бетерә торган авыру.
4. Акылны җиңеләйтә һәм төрле аңсыз сүзләр сөйләтә торган картлык.
5. Кисәк килергә мөмкин булган үлем.
6. Ирешергә мөмкин булганнарның иң начары булган — Дәҗҗал.
7. Кыямәт көне. Кыямәт коненең афәте иң куркынычы һәм ачысы.

**Рөстәм хәзрәт Шәйхевәли,**
**Чаллының "Ак мәчет"е имам-хатыйбы**

---

# Сорау вә җавап

Исәнмесез, кадерле дин кардәшләрем!

Сездән мине күптән борчыган сорауларга җавап аласы килә иде. Сүз хәрам белән хәләл турында. Инде хәтерләмим, кайсы елгыдагыдыр дини календарьда укып, кондитер изделиеләрендә хәрам һәм шикле Е кушымтасын белгән идем. Мин аларны язып алып кошелокка салып куйдым. Кибетләргә кереп печеньеләрне, пряник, конфетларны, туңдырма, маргариннарны карый башлаган идем, күбесендә E471, E120, глицерин, диглицерин кушылганны ачыкладым. Димәк, бу ризыкларны мөселман кешегә кулланырга ярамый? Менә ул Елларның тезмәсе:

E 120, E 1200 – хәрам.

E 132, E422, E471, E472a, E472b, E472, E 472c, E472d, E472 g, E 478 – шикле.

Минем өч соравыма җавап бирсәгез бик канәгать булыр идем. Чөнки бүтән кешеләр дә белсеннәр иде.

1. Шушы Е лар кушылган ризыклар хәрам булалармы?
2. Сабында да хайван мае кулланыла, ул да хәраммы?
3. Чәч тарагач, коелган чәчләрне яндырырга ярыймы?

Алдан ук сезгә зур рәхмәтләр белдереп,

**Башкортостанның Борай районы,**
**Кәшкәләү авылыннан**
**Зилә Шәһәбетдинова.**

**1. Нәрсәне дә булса тыю өстенлеге фәкать Аллаһы Тәгаләгә генә хас. Ошбу хакта Коръәндә болай диелә: "Аллаһыга ифтара (яла ягу) кылмас өчен, дәлилсез, үз белдегегез белән : "бу хәрам" вә "бу хәләл" дип әйтмәгез! Чөнки хәләл, хәрам кылучы – Алаһы Тәгаләдер. Аллаһуга ялганны ифтира кылучылар газаптан котыла алмаслар" (16:116).**

**Коръәндә тыелган катнашмалары булган теләсә нинди продукт (кан, эрен, үләксә, шәраб, дуңгыз) хәрам булып исәпләнә. Сорауда китерелгән Е 471 компоненты үсемлектән яки терлек чималыннан ясалырга мөмкин. Шуңа күрә аны җитештерүченең үзеннән генә ачыклап була.**

**2. Исламда истихалә (бер хәлдән икенче хәлгә күчү) дигән төшенчә бар. Башлангыч хәлендә хәрам булган нindидер матдә эшкәртү процессында үзенең башлангыч сыйфатларын югалтса, химик структурасын үзгәртсә, ул хәләлгә әйләнергә мөмкин. Мисалга шәрабның уксус кислотасына әверелүен китерергә була. Шушы кагыйдәгә нигезләнеп Хәнәфи мәзһәбе галимнәре терлек компонентлары кушып эшләнгән сабынның хәләл булуына фәтва бирәләр. Чөнки ул эшкәртүгә дучар ителә, үзенең баштагы сыйфатын югалта. Шуны да әйтергә кирәк, бүгенге көндә терлек мае кулланмыйча җитештерелә торган сабыннар да бар.**

**3. Пәйгамбәребез салл-Аллаһу галәйһи вә сәлләм чәч бөртекләрен, тырнакларын, шулай ук канлы бәйләвечләрне (чүпрәк кисәкләре, мамык, салфетка) җиргә күмә торган булган. Моны авыл шартларында эшләргә була, әмма ул шәһәр шартларында мөмкин түгел. Шуңа күрә аларны чүп-чар контейнерларына ташлау җиргә күмүгә тиңләнә. Чөнки чүп-чар чүплекләргә ташыла һәм соңыннан ул җир белән күмелә.**

**Тырнакларны кисүнең аерым көне юк. Аны һәм башка гигиена процедураларын атна саен эшләү хәерле.**

*Укучыбыз соравына җавапны ҮДО-Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте каршындагы Хәләл стандарты буенча комитет белгече Илгиз Баһаветдинов бирде.*

---

## Намаз турында

Көнгә биш кат манарадан
Азан намазга чакыра;
Намаздан соң күңелләрең
Вә йөзләрең яктыра.

Табигатьнең гүзәл чагы
Әлбәттә, диләр, яздыр;
Гыйбадәтнең саваплысы
Иманнан соң намаздыр.

Шушы изге гыйбадәтне
Тотсаң калдырмый бер дә,
Бакыйлыка күчкәч булыр
Тәмугъ утыннан пәрдә.

Үлеп гүрләргә кергәч тә
Әүвәл намаз соралыр;
Намазы бары оҗмахка
Югы тәмугъта калыр.

Намаз Кыямәт көнендә
Сиңа шаһитчы булыр;
Белеп, белмәенчә кылган
Гөнаһларың юылыр.

Коръән укый белмәсәң дә
Намаз укырга тырыш;
Аллабызның каршысында
Ул безнең изге бурыч.

Намаз мөэмин-мөселманның
Иңдер изге догасы;
Савап эзләп юлга чыккан
Хаҗиларның кыйбласы.

Намаздыр җәннәт ачкычы
Вакытында укылган;
Дин иясе дә Алладыр
Безне юктан бар кылган.

Көн дә намаз укымасаң
Бераздан онытыла;
Тик ятып азган күңелең
Шайтаннарга омтыла.

Намаз ул диннең терәге,
Ул фарыз гамәл безгә;
Кыямәт көндә кызыллык
Китермик йөзебезгә.

Намаз хәтерне яңарта
Яман уйларга киртә;
Күңел төшенке чагында
Яктыга, нурга илтә.

Намаз ашаганда бирә
Ризыгыңа бәрәкәт;
Исәнлегең өчен дә ул
Күнегүләр, хәрәкәт.

Сабырлык бәхет иясе
Бәхет гаиләнеке;

Намазның изге савабы
Укысаң ул синеке.

Намаз укып юлга чыксаң
Уңышлы булыр юлың;
Бәлаләргә юлыкмассың,
Сызламас аяк-кулың.

Намаз ул Аллаһ бүләге,
Яраткан кәбеленә;
Укыган иманда калыр
Кергәч үз каберенә.

Азан тавышы яңгырый
Зәңгәр күктә кичләрен;
Бакыйлыкта юлдаш булыр
Намазга бирелгән хисләрең.

Без белеп тә бетермибез
Савапларын намазның;
Белмәгән кебек серләрен
Тиздән киләсе язның.

Намаз ул Аллаһ нигъмәте
Безгә өстән бирелгән;
Кичекми намазга баса
Чиреннән дә терелгән.

Иртәнге намазыңдагы
Теләгең эшкә ашар;
Намаз укымаган өйдә
Шайтаннар, ди, туй ясар.

Намаз бит ул җан азыгы
Яшәгән гомереңдә;
Имансыз булып китәсен
Теләмидер берең дә.

Мәчет булып та намазлар
Көнгә бер укылмаса;
Шайтан йортына әйләнеп
Тирә-ягын чүп баса.

Кайда йөрмә күңелеңдә
Туып-үскән ягыңдыр;
Аллаһыга якынаюың
Намаздагы чагыңдыр.

Намазда алган гыйлемең
Синнән балаңа күчәр;
Изге гамәл кылган гына
Сират күперен кичәр.

Намаз ул милләтебезнең
Көн күреше, язмышы;
Ходай безне аермасын
Иде гамәлдән шушы.

**Сафиулла Әһлиуллин**
**Оренбург өлкәсе, Әсәкәй районы,**
**Иске Мөэмин авылы.**

# Кукмара мәдрәсәсе: үткәне, бүгенгесе



Кукмара мәдрәсәсе тарихының тамырлары 1994 елга тоташа: ул вакытта Үзәк мәчет каршында барлык теләүчеләрне ислам нигезләре белән таныштыруны максат итеп куйган якшәмбе мәктәбе эшли башлый. 1998 елда дин белемен билгеле бер тәртипкә салу нияте белән мәчет активы рәсми дини уку йорты булдырып, рәсми теркәлергә кирәк дигән фикергә килә. Кирәкле документлар әзерләнгәч, Татарстан Республикасының юстиция министрлыгына гариза язылa һәм 1998 елда мәдрәсә рәсми дини уку йорты буларак теркәлә.

10 ел дәвамында мәдрәсә Үзәк мәчет бинасында башлангыч дини уку йорты буларак эшли. Атна дәвамында



кукмаралылар, ял көннәрендә исә авылда яшәүчеләр килеп дини гыйлем эсти.

2008 елның декабрь аенда мәдрәсәнең яңа бинасы сафка баса һәм 2009 нчы елдан шәкертләрне шул яңа бинада укыта башлыйлар. Шартлар яхшыргач, мәдрәсә җитәкчелеге урта-махсус, һөнәри дини уку йорты буларак эшләргә мөмкинлек бирә торган Лицензия алуны максат итеп куя. Аллаһның рәхмәте белән 2010 елның апрель аенда Фән һәм мәгариф министрлыгы тарафыннан әлеге Лицензия бирелә. Шуннан соң урта махсус профессиональ юнәлештә эшләүче бүлек булдырыла. Аның белән бергә Башлангыч бүлек тә үз эшен дәвам итә. Әлеге бүлектә уку 3 ел дәвам итә, шушы вакыт эчендә 10 лап фәнне өйрәнү каралган. Кичке бүлектә исә фәннәр саны инде 20 гә җитә (дини фәннәрдән тыш, бу бүлектә кайбер дөньяви фәннәр дә укытыла). Аны тәмамлаучыларга “Имам-хатыйб” (ир-егетләргә) һәм “ислам нигезләре мөгаллиме” (хатын-кызларга) дигән квалификация бирелә. Әлеге программаны шәкертләр 4 ел дәвамында үзләштерәләр.

Мәдрәсәдә бүген урта һәм югары дини һәм дөньяви белемгә ия булган тәҗрибәле мөгаллимнәр эшли. 1998 елдан әлеге уку йорты белән мөгаллим, дини дәреслекләр һәм әдәби әсәрләр авторы, язучы һәм журналист Ришат хәзрәт Курамшин җитәкчелек итә. Укытучыларның төп составы 15 кешедән тора, алардан тыш чакыру буенча, сәгатьләп кенә дәрес бирүче мөгаллимнәр дә бар. Дини фәннәрдән белем бирүче мөгаллимнәрнең күбесе “Мөхәммәдия” мәдрәсәсендә дини гыйлем алган, 4 мөгаллим Казандагы Россия Ислам Институтын тәмамлаган. Моннан тыш мәдрәсә остазлары төрле белем күтәрү курсларында да катнашалар.

Кукмара мәдрәсәсе эшләү дәверендә барлыгы 17 чыгарылыш булды (2016 елгы мәгълүмат). Шул вакыт эчендә мәдрәсәнең башлангыч бүлеген 1242, һөнәри бүлекне исә 120 — барлыгы 1362 кеше тәмамлады. Быел мәдрәсәнең һөнәри бүлеген 27 кеше (19 ир-егет һәм 8 хатын-кыз) тәмамлый. Башлангыч бүлекне тәмамлаучылар саны — 53 (42 олы кеше һәм 11 яшүсмер). Мәдрәсәне тәмамлаучылар арасында дин өлкәсендә хезмәт итүчеләр дә байтак, әйтик, Кукмара районындагы 70 ләп мәхәлләнең 40 да Кукмара мәдрәсәсен тәмамлаган ир-егетләр имам вазифасын башкара. Авылларда эшләп килүче мәчет каршындагы курсларда да башлыча Кукмара мәдрәсәсендә белем алган шәкертләр халыкка башлангыч дини белем бирә.



Соңгы елларда мәдрәсәдә белем алучыларның яшәү урыны географиясе киңәя бара: бирегә Кукмара бистәсендә һәм районында гына түгел, күрше район һәм төбәкләрдә яшәүчеләр дә белем алырга килә.

Уку елы дәвамында шәкертләр белем алу белән генә чикләнми: алар катнашында төрле кызыклы чаралар — бәйгеләр, викториналар үткәрелә (әйтик, ир-егетләр төркемнәре арасында



“Мөслимнәр бәйгесе”, хатын-кызлар төркемнәре арасында исә “Мөслимәләр бәйгесе”). Дини бәйрәмнәр, истәлекле вакыйгалар вакытында чәй мәҗлесләре оештырыла. Мәүлид аенда, ягъни Мөхәммәд пәйгамбәр гәләйһиссәләм туган айда әлеге чәй мәҗлесләре эчтәлекле вәгазьләр белән үрелеп бара. Элекке елларда мәдрәсәне тәмамлаучылар да төркемнәре белән җыелып чәй мәҗлесләре оештыруны гадәткә кертте. Шулай итеп, алар белән дә элемтә өзелми. Мөгаллимнәр һәм шәкертләр, өлкәннәр һәм яшьләр — төрле буын вәкилләре — шулай аралашып, гыйлем уртаклашып, ярдәм итешеп яши. Аларны ислам диненә мәхәббәт, дини белем алу теләге һәм ихлас иман



берләштерә. Үзләрендә мондый дини белем учагы булуына кукмаралылар сөенеп бетә алмый. Аллаһы Тәгаләгә шөкер хисләрен белдереп, алар шатлыкларын уртаклашып, болай ди:

*Менә шулай бик күңелле яшибез без*
*Мәдрәсәдә — гыйлем юлында.*
*Дини белем безне зур Бәхеткә илтә,*
*Аның чишмә башы Кукмарада...*

**Рәсемнәрдә:** мәдрәсәнең төнге күренеше; Ришат хәзрәт (уңда) газетабыз нәшире Иршат хаҗи белән әңгәмә вакытында; уку сыйныфларында.

**Нәшире**
**Иршат Гыйльметдин улы ШӘЙХАТТАР**

**Баш мөхәррире**
**Хәлил ШӘРИФ**

**Тел.:** (8552) 70-51-09
**Факс:** (8552) 70-51-45

* * *

**Оештыручылары:**
Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан җөмһүрияте мөселманнары Диния нәзарәте, “Ислам нуры” дини эшмәкәрлек Үзәге

Газетабыз мәкаләләрен күчереп басканда аларның “Ислам нуры”ннан алынганын күрсәтү мәҗбүри.

Редакциягә килгән язмалар игътибар белән өйрәнелә, рецензияләнә. Хатлар газетага әзерләнгәндә авторларның стиле саклана.

**Хатларны 423802, Чаллы Үзәк ур., 72 адресы буенча юллау кирәк.**

**Электрон хатлар өчен:**
**e-mail: islamnury@mail.ru**

Мөселманнар арасын бозуга, үзара каршылыкларга китерергә мөмкин булган хатлар, шикаятьләр газетада басылмый.

Дин-шәригать мәсьәләләренә кагылышлы язмалар, укучылар сораулары Татарстан Диния нәзарәтенең баш казые, Чаллы төбәге мөхтәсибәтенең гыйльми Советы тарафыннан өйрәнелә һәм аларга җаваплар бирелә.

Россия Федерациясе матбугат, телерадиотапшырулар һәм массакүләм коммуникацияләр Министрлыгының Идел буе төбәкара территориаль идарәсендә ПИ № 7-0997 саны белән 2001 елның 15 ноябрендә теркәлде.

“Роспечать” агентлыгы каталогына кертелгән, язылу ел әйләнәсендә Россия Федерациясе буенча алып барыла.

Айга ике мәртәбә чыга.

**Тиражы 1100.**
**Индексы 54149**

* * *

Хөрмәтле укучыбыз!

Газетабызны укып чыккач, аны туганнарыгызга, танышларыгызга, алай дабулмаса башка мөселманнарга тапшырсагыз иде. “Ислам нуры”ның һәр саны кулдан-кулга күчеп динебезне таратырга ярдәм итсә иде. Әмин.

Шулай ук укучыларыбыз, Коръән аятьләре язылу сәбәпле, газетабызны кирәкмәгән урыннарга ташлаудан сакланырлар дип ышанабыз.

* * *

Газета компьютерда җыелды, офсет ысулы белән “Ислам нуры” басмаханәсендә басылды.

Нәшир һәм редакция адресы:
**423802, Яр Чаллы, Үзәк урамы, 72**

**Басарга кул куелды:**
**график буенча**
**25 апрель 16 сәг.**
**фактта 25апрель 16 сәг.**

**Бәясе ирекле**